| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2021 Әгерҗе шәһәре № 7-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен тыңлап, фикер алышканнан соң, билгеләнгән тәртиптә бастырылган иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсен һәм нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясы нигезендә килештерү процедурасын уздыру нәтиҗәләре буенча килештерү комиссиясе беркетмәсен исәпкә алып, Красный бор авыл җирлегенең Генераль планы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24 маддәсе нигезендә эшләнгәнен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «ТАТИНВЕСТГРАЖДАНПРОЕКТ» Баш территориаль проект-тикшеренү, фәнни-җитештерү фирмасы Татарстан Республикасы Дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан эшләнгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлегенең кушымтадагы Генераль планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлеге Советына үз көчләрен югалткан дип танырга тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Краснобор авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный бор авыл җирлеге» генераль планын раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 37-2 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Краснобор авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный бор авыл җирлеге» генераль планын раслау турында» 2012 елның 30 ноябрендәге 19-3 номерлы карары.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, «Татмедиа» АҖ филиалының

«Әгерҗе хәбәрләре» газетасында вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев